**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Нырья авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**10 ноябрь, 2025 ел** **№ 4**

**«Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Иштуган авылында гражданнарның үзара салым чараларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2025 елның 25 ноябрендә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Нырья авыл җирлегенең Иштуган авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Балды-Кня авылы, Гагарин ур., 12 адресындагы авыл клубы бинасында уздырырга.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Сез 2026 елда Кукмара муниципаль районының Нырья авыл җирлеге Иштуган авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 1 төркем инвалидларыннан; көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлардан (курсантлардан); 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аналардан; 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз аталардан, 80 яшькә җиткән һәм аннан өлкәнрәк затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә сроклы хәрби хезмәткә чакырылган затлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала, 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Иштуган авылының Куйбышев урамы юлын төзү, ремонтлау, карап тоту, вак таш җәю (проект-смета документларын эшләү, техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, вак таш сатып алу, ташу, салу, килешү буенча эш өчен түләү);

- урам яктырту җайланмасы (урам яктырткычлары сатып алу һәм урнаштыру, проект-смета документларын эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, килешү буенча эш өчен түләү)?

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Нырья авылы башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә кабул ителгәннән соң 5 көн эчендә урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Нырья авыл җирлеге башлыгы урынбасары: Р.П. Павлов